# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы
Әтрәкле авыл җирлегенең Чупай торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында

**2020 елның 09 ноябре** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 09 ноябрендә узган халык җыены нәтиҗәләре белән халык җыенының йомгаклау беркетмәсе түбәндәге мәсьәлә буенча тәзелде: "2021 елда Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Әтрәкле авыл җирлегенең Чупай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 500 сум күләмендә (1,2 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннары, күпбалалы гаиләләр, көндезге бүлектә укучы студентлар, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш) үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә Сез ризамы?":

1) Чупай торак пунктында суэтем башнясы территориясен төзекләндерү (суэтем скважинасына металлдан эшләнгән будка урнаштыру, электр җиһазларын яңадан урнаштыру, эшләр өчен килешү нигезендә түләү);

2)Чупай торак пунктында Мөшеге елгасы аша җәяүлеләр күперен ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, эшләр өчен килешү нигезендә түләү).

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган катнашучылар исемлегенә 72 халык җыенында катнашучы кертелгән, халык җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны – 40 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
җыенда катнашкан 40 кеше «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар бирде:

1. Минзәлә муниципаль районы Әтрәкле авыл җирлегенең Чупай торак пунктында халык җыены узуын таныйрга, халык җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип таныйрга.

2. "2021 елда Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Әтрәкле авыл җирлегенең Чупай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 500 сум күләмендә (1,2 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннары, күпбалалы гаиләләр, көндезге бүлектә укучы студентлар, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш) үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә Сез ризамы?" мәсьәләсе буенча карарны таныйрга:

1) Чупай торак пунктында суэтем башнясы территориясен төзекләндерү (суэтем скважинасына металлдан эшләнгән будка урнаштыру, электр җиһазларын яңадан урнаштыру, эшләр өчен килешү нигезендә түләү);

2)Чупай торак пунктында Мөшеге елгасы аша җәяүлеләр күперен ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, эшләр өчен килешү нигезендә түләү).

3. Әтрәкле авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән халык җыены нәтиҗәләрен кабул ителгән көннән 7 көн эчендә Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында (https://menzelinsk.tatarstan.ru/atraklinskoye.htm) хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Әтрәкле авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

**Халык җыенында рәислек итүче**
**Минзәлә муниципаль районы**
**Әтрәкле авыл җирлеге башлыгы**

**Р. Ш. Газизҗанов**